**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Единение авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

«19» октябрь 2023 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 19 октябрендә узган: «2024 елда Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге Единение авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү;

- зират тирәсен койма белән тоту.» мәсьәләсе буенча халык җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 34 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 25 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 25 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Единение авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2024 елда Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге Единение авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү;

- зират тирәсен койма белән тоту.» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Единение авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.И.Борисов

Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов